Эшне үтәү буенча кулланма

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 12 биремне үз эченә ала (А1-А12), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган җавапны сайлап алырга тиеш.

Икенче өлеш В1-В6 биремнәреннән тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. В1-В6 биремнәренә җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиешсез.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыксса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. Беренче өлештәге биремнәргә якынча 2 минут вакыт бирелә. Икенче өлештәге һәр биремгә 3-4 минут вакытыгызны сарыф итегез.

Дөрес җаваплар, катлаулылыкларыннан чыгып, 1 яки югарырак баллар белән бәяләнәләр. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезгә гомуми балл чыгарыла, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Сезгә уңышлар телибез !

2 вариант

1 өлеш (А)

Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А12) үтәгәндә, җавалар бланкында эшләнә торган бирем аста урнашкан, дөрес дип табылган җавап номеры шакмагына «Х» билгесе куегыз.

А1. Калын сузык авазлардан торган сүзләр рәтен билгеләгез.

1. кар, китап, күз, орчык
2. зиһен, очучы, пакет, чәкчәк
3. кыяр, арыслан, зал, каен
4. мич, миң, килен, йөзем

А2. Яңгырау тартыклардан торган сүзне билгеләгез.

1. катык
2. мәгънә
3. чиләк
4. табигать

А3. Хаталы сүз булган рәтне табыгыз.

1. зирәк, хат, җиләк, маңгай
2. волейбол, завод, пароход, витамин
3. дингез, кибет, ябалак
4. яшьлек, тиен, һәм

А4. Кайсы рәттәге сүзләрдә ъ хәрефе языла?

1. сәнгат..., п...еса, дөн...я
2. аш...яулык, иг...лан, вәг...дә
3. кул...яулык, көн...як, кәгаз...
4. кур...ер, роял..., ик...рар

А5. **Кайсы рәттәге сүзләргә** – *лар, - ләр* **күплек кушымчалары ялгана?**

1. диңгез, кибет, малай
2. үлән, куян, бүре
3. кеше, ябалак, миң
4. урман, тиен, идән

А6. **Ясагыч кушымчалары булмаган сүзләр рәтен күрсәтегез.**

1. бишлек, сөенеч, такталы
2. бишенче, сөлге, туктадык
3. ямьләнгәч, берләштек, хәйләле
4. күзлек, китаплы, кыргыч

А7. Парлы сүзләр булган рәтне билгеләгез.

1. көнкүреш, ташбака, ашханә
2. хатын-кыз; тирә-як, кием-салым
3. уйлы, көчле, яңгырлы
4. эт тырнагы, үги ана яфрагы, кура җиләге

А8. Бирелгән җөмләдән тартымлы исемнәрне күрсәтегез.

Бакчабыздагы куе кура җиләкләре арасында ел саен берәр кошчык ояламый калмый. (Р.Гариф)

1. ел, кошчык
2. куе, кура
3. бакчабыздагы, кура җиләкләре
4. бакчабыздагы, берәр

А9. **Бирелгән мәкальдәге рәвешнең антонимын табыгыз.**

Иптәшең үзеңнән яхшы булсын.

1. начар
2. әйбәт
3. бик яхшы
4. яхшырак

А10. **Түбәндәге җөмләнең хәбәрен табыгыз.**

Җылы яклардан кошлар кайталар.

1. җылы
2. кошлар
3. кайталар
4. яклардан

А11. **Төшеп калган сүзне табыгыз.**

“... предметны белдерәләр. Алар кем? нәрсә?” соравына җавап бирәләр.

1. фигыльләр;
2. исемнәр;
3. хәбәрләр;
4. сыйфатлар.

А12. Микъдар саны нәрсәне белдерә?

1. предметның төгәл исәбен
2. предметның саналу тәртибен
3. предметның билгесен
4. предметның эшен, хәрәкәтен

2 өлеш (В)

Әлеге өлештәге биремнәрне, тәкъдим ителгән текст ярдәмендә үтәгәндә, җавапларыгызны җавап бланкында В1-В6 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга ярамый.

1) Идел өстендә җил уйный. (2) Бер-берсен куышкан шаян дулкыннар ярга килеп бәреләләр, шаулашалар.(3) Елга өстендә акчарлаклар оча.(4) Алар суга уктай атылалар, балык тоталар.(5) Акчарлаклар армыйлар.

В1. 2 нче җөмләдәге сыйфатның антонимын языгыз.

В2. 4 нче җөмләдәге ясалма сүзне язып алыгыз.

В3. Текстан алмашлыкны табып языгыз.

В4. 3 нче җөмләдән юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзне язып алыгыз.

В5. 1 нче җөмләнең иясен табыгыз һәм юнәлеш килешенә куеп языгыз.

В6. 3 нче җөмләдәге аваз саны хәрефкә караганда күбрәк булган сүзне табып языгыз.